**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**422610 г.Лаишево,**
**ул. Первомайская, д.39**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ район СОВЕТЫ**

**422610 Лаеш ш.,**
**Беренче май урамы, 39 нчы йорт,**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

**2023 елның 25 декабре** **149-РС номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү Проектын раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының 2023елның 20 декабрендәге 10-53/16003 номерлы Столбище авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты бәяләмәсен, 2023елның 30 ноябрендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне карап, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карар чыгарды**:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге генераль планына үзгәрешләр кертү проектын (1 нче кушымта) расларга.
2. Әлеге карарны “Кама ягы” («Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары И. П. Шитовка йөкләнә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы Рәисе вазыйфаларын башкаручы** **Т.П.Борһанова**